КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 54

Төбәк кан тамырлары үзәкләрен һәм беренчел кан тамырлары бүлекләрен җайланма белән җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төбәк кан тамырлары үзәкләрен һәм беренчел кан тамырлары бүлекләрен җайланма белән җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 ел, 30 декабрь, 1771 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Төбәк кан тамырлары үзәкләрен һәм беренчел кан тамырлары бүлекләрен җайланма белән җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен;

төбәк кан тамырлары үзәкләрен һәм беренчел кан тамырлары бүлекләрен җайланма белән җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән медицина җайланмасы белән җиһазландырылырга тиешле медицина оешмалары исемлеген.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 гыйнвар, 54 нче
карары белән расланды

Төбәк кан тамырлары үзәкләрен һәм беренчел кан тамырлары бүлекләрен җайланма белән җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы медицина оешмалары базасында урнашкан төбәк кан тамырлары үзәкләрен һәм беренчел кан тамырлары бүлекләрен җайланма белән җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан (алга таба – шул ук эзлеклелектә медицина оешмалары, акча) файдалану механизмын билгели.

2. Акча, медицина эшләнмәләренең технологик тасвирнамәләре эквивалент булганда Россия җитештерүчеләренең медицина эшләнмәләренә өстенлек бирүне исәпкә алып, медицина оешмаларын Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлек буенча медицина ярдәме күрсәтү тәртипләрендә каралган җиһазландыру стандартлары нигезендә медицина эшләнмәләре (алга таба – медицина җайланмасы) белән җиһазландыруны күздә тота торган өлештә Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе законнары белән бирелгән вәкаләтләр кысаларында медицина ярдәмен үстерү һәм гражданнарга аннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өчен шартлар тудыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу (шул исәптән тулы күләмдә) максатларында бирелә.

3. Акчаны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу Тәртипнең 2 нче пункты нигезендә медицина оешмаларын җиһазландыру өчен Россия Федерациясенең медицина җайланмасы сатып алуга дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнары нигезендә дәүләт килешүләре (шартнамәләре) төзи.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән акча керү турында мәгълүмат алганнан соң Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына финанслауның иң чик күләмнәрен ирештерүгә чыгым расписаниясен әлеге Идарәгә билгеләнгән тәртиптә кертә.

6. Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең акча керү турындагы хәбәр итү кәгазьләре нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы финанслауның ирештерелгән иң чик күләмнәре чикләрендә медицина оешмаларын җиһазландыру өчен медицина җайланмасы

сатып алуга дәүләт килешүләре (шартнамәләре) төзелгән оешмаларга дәүләт килешүләре (шартнамәләр) шартлары нигезендә акча күчерүне гамәлгә ашыра.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасына түбәндәгеләрне урнаштыра:

финанслашуга (шул исәптән тулы күләмдә) акча бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турындагы хисапны – хисап аеннан соң килүче айның 10сыннан да соңга калмыйча, ай саен;

акчадан файдалану нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисапны – хисап аеннан соң килүче айның 10сыннан да соңга калмыйча, ай саен.

8. Акчадан максатчан файдаланмау Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына акчаның файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 гыйнвар, 54 нче
карары белән расланды

Төбәк кан тамырлары үзәкләрен һәм беренчел кан тамырлары бүлекләрен җайланма белән җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән медицина җайланмасы белән җиһазландырылырга тиешле медицина оешмалары
ИСЕМЛЕГЕ

2019 ел:
«Төбәкара клиник-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба – ДАСУ),
«7нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ, Казан шәһәре,
«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАСУ,
«Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАСУ.

2020 ел:
«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАСУ,
«Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАСУ,
«Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАСУ,
«5 нче шәһәр хастаханәсе» ДАСУ, Яр Чаллы шәһәре.

2021 ел:
«Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАСУ,
«Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАСУ,
«Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАСУ,
«Буа үзәк район хастаханәсе» ДАСУ,
«Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАСУ.

___________________________